КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 август г.Казань № 640

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда вагон-хопперлар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 28 август, 1031 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда вагон-хопперлар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 28 август, 1031 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2023 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «2023 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2023 елда вагон-хопперлар сатып алуга бәйле чыгымнар өлешен каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә «2023 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта:

исемендә «2023 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасында «2023 елда» сүзләрен «2023 елның 1 гыйнварыннан соң кайтарулар (сату-алу) шартнамәләре буенча, шулай ук 2024 елның 1 гыйнварыннан соң финанс арендасы (лизинг) килешүләре буенча» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия агымдагы финанс елында һәм (яисә) агымдагы финанс елына кадәрге елда сайлап алуда катнашучыларның тотылган чыгымнары өлешен каплауга бирелә, әгәр алар алданрак түләнмәгән булса.»;

2 пунктның беренче абзацында «2023 ел» сүзләрен «тиешле финанс елы һәм план чоры» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«икътисадый эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру - тимер юл транспорты эшчәнлеге: йөк ташулар.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы https:://subsidiya.tatar.ru яки https:://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада языла торган заявка тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмә кәгазе;

кайтарулар (сату-алу) килешүләре буенча субсидияләр алу өчен:

вагоннарны кайтару (сату-алу) килешүләрен;

вагоннарны кабул итү-тапшыру актлары;

товар накладнойлары, счетлар-фактурлар йә кайтару (сату-алу) шартнамәләре буенча универсаль тапшыру документлары (УТД);

вагоннар бәясен түләүне раслый торган түләү банк документлары;

түләү өчен счетлар (әгәр түләү өчен счет түләү йөкләмәсендә күрсәтелгән булса);

кайтару (сату-алу) шартнамәләре буенча Россия Федерациясе Статистика буенча дәүләт комитетының «Төп чараларны исәпкә алу буенча беренчел исәпкә алу документациясенең унификацияләнгән формаларын раслау турында» 2003 елның 21 гыйнварындагы 7 номерлы карары белән расланган «Төп чаралар объектын кабул итү-тапшыру турында акт (биналардан, корылмалардан башка)» дигән ОС-1 номерлы форма;

вагоннар паспортлары;

Таможня берлегенең «Тимер юл хәрәкәте составы иминлеге турында» техник регламентына вагоннарның туры килү сертификатыhttp://consultant.mship.local:8080/?req=doc&base=LAW&n=444499&dst=3301&field=134&date=21.11.2023;

субсидия бирелгән елдан башлап, 10 ел эчендә вагоннар белән Татарстан

Республикасында җитештерелгән ашлыкны ташу турында йөкләмәләр;

субсидия бирелгән елдан башлап, 10 ел эчендә вагоннарны читләштермәү һәм аларны арендага бирмәү турында йөкләмәләр;

финанс арендасы (лизинг) килешүләре буенча субсидияләр алу өчен:

вагоннарны файдалануга алу максатларында төзелгән финанс арендасы (лизинг) килешүләре;

вагоннарны кабул итү-тапшыру актлары;

лизинг түләүләрен түләүне раслый торган түләү банк документлары;

түләү өчен счетлар (әгәр түләү өчен счет түләү йөкләмәсендә күрсәтелгән булса);

вагоннар паспортлары;

Таможня берлегенең «Тимер юл хәрәкәте составы иминлеге турында» техник регламентына вагоннарның туры килү сертификатыhttp://consultant.mship.local:8080/?req=doc&base=LAW&n=444499&dst=3301&field=134&date=21.11.2023;

субсидия бирелгән елдан башлап, 10 ел эчендә вагоннар белән Татарстан Республикасында җитештерелгән ашлыкны ташу турында йөкләмәләр;

субсидия бирелгән елдан башлап, 10 ел эчендә вагоннарны читләштермәү һәм аларны арендага бирмәү турында йөкләмәләр.

Һәр вагонның, фотога төшерелгән датасын күрсәтеп, төсле фотосурәтләрен теркәргә кирәк.

Сервис  автоматлаштырылган режимда ала торган документлар:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән критерийга һәм әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган өземтә;

сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе.

Сайлап алуда катнашучы заявкаларны кабул итү тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка кергән көнендә чират тәртибендә теркәүгә алына.»;

13 пунктта «вагоннар» сүзеннән соң «һәм (яисә) лизинг түләүләре өчен түләү» сүзләрен өстәргә;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Бу Тәртипнең 1 пункты нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (W1) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_1 = (S \times 30\%) + (L \times 30\%),$$

монда:

S - 2023 елның 1 гыйнварыннан соң кайтарулар (сату-алу) шартнамәләре буенча

сатып алынган вагоннарны түләү буенча фактик чыгымнар, өстәлгән бәягә салымны, монтажны, транспорт хезмәтләрен түләүгә чыгымнарны тотып калганнан соң;

L - 2024 елның 1 гыйнварыннан соң финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре буенча сатып алынган вагоннар өчен фактта түләнгән лизинг түләүләре, өстәлгән бәягә салымны, монтажны, транспорт хезмәтләрен түләүгә чыгымнарны тотып калганнан соң.

Бирелә торган субсидиянең күләме бер вагонга 2,0 млн. сумнан арта алмый.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен субсидияләр бирүнең түбәндәге нәтиҗәсе кулланыла: субсидия бирү елына кадәр 10 ел элек Татарстан Республикасында җитештерелгән кайтарылган ашлык күләменә ирешелде, тонналарда.»;

17 пунктның алтынчы абзацында «2023» саннарын «хисап финанс» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин